СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-60, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**12 декабрь, 2025 ел** **№ 23**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, ай саен һәм башка өстәмә түләүләрнең күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, ай саен һәм башка өстәмә түләүләрнең күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарына (23.09.2020 № 4, 12.11.2021 № 122, 31.03.2022 № 156, 12.10.2022 № 212, 21.11.2022 № 225, 28.06.2024 № 418, 09.10.2024 № 446, 30.04.2025 № 517 белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.1 пунктта «15 389» саннарын «16 928» саннарына алмаштырырга.

2.1 «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфалар биләүче затларга, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының контроль-хисап органы рәисенә хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары» 1 нче кушымтасындагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 төркем |
| Муниципаль район башлыгы | 44 814 |
| Муниципаль район башлыгы урынбасары | 40 334 |
| Муниципаль районның контроль-хисап органы рәисе | 40 334 |

2.2 «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре» 2 нче кушымтасындагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| N т/б | Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|---|
| | | 8 төркем |
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе | 44 013 |
| 2. | Совет аппараты җитәкчесе | 39 950 |
| 3. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 39 612 |
| 4. | Башка җирле үзидарәнең органы җитәкчесе | 39 442 |
| 5. | Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 36 226 |
| 6. | Башкарма комитет эшләр идарәчесе | 37 072 |
| 7. | Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), башка структур бүлекчә (аппарат) җитәкчесе | 30 809 |
| 8. | Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары, башка структур бүлекчә җитәкчесе урынбасары | 26 916 |
| 9. | Муниципаль район башлыгы ярдәмчесе | 26 916 |
| 10. | Сектор мөдире | 24 884 |
| 11. | Баш белгеч | 23 869 |
| 12. | Әйдәп баручы белгеч | 22 176 |

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталы рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының бюджет, финанс һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов